| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**15.03.2021** г. Казань **№ 59**

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәтенең вазифасын алмаштыруга (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы Яшьләр эшләре министрлыгының 2018 елның 13 июленнән 3 номерлы приказы нигезендә расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәтенең вазифасын алмаштыруга (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү

2004 нче елның 27 июлендәге «Россия Федерациясенең дәүләт гражданнар хезмәте турында»гы 79 номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге «Россия Федерациясенең дәүләт гражданнар хезмәтенең вазифасын алмаштыруга конкурс уздыру турында»гы 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартындагы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазифаларын алмаштыруга һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында»гы 397 номерлы карары нигезендә **боерам:**

1. «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәтенең вазифасын алмаштыруга (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы Яшьләр эшләре министрлыгының 2018 елның 13 июленнән 3 номерлы приказы нигезендә расланган Татарстан Республикасының Яшьләр

эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәтенең вазифасын алмаштыруга (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Конкурс дәүләт граждан хезмәте вазифасын алыштыруга дәгъва итүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен (алга таба - граждан хезмәте), аларның граждан хезмәте вазифасын алу өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.»;

2.4 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) вәкаләтле гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәләреннән һәм Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар - фәнни, белем бирү һәм башка оешма вәкилләре, кадрлар технологияләре һәм гражданлык хезмәте мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә чакырылалар. Бәйсез экспертның Конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.»;

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Конкурс комиссиясе тарафыннан утырыш үткәрү видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) булырга мөмкин дигән карар кабул ителергә мөмкин. Мондый карарның сәбәбен (нигезләвен) күрсәтеп, аның әгъзасы яисә кандидаты тәкъдиме буенча кабул ителә.»;

2.9 пунктта «конкурс комиссиясе рәисе» сүзләрен «утырышта рәислек итүче» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктының «г» пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш)»;

өченче абзацта «эш (хезмәт) урыны буенча» сүзләрен «хезмәт (эш) урыны буенча» сүзләренә алмаштырырга);»;

4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Кандидатларны конкурс процедуралары барышында бәяләү өчен әлеге нигезләмәнең 3 нче, 4 нче кушымталарында күрсәтелгәннәр арасыннан бәяләү методлары кулланыла. Шул ук вакытта кандидат белән тест һәм шәхси әңгәмә барлык кандидатлар өчен мәҗбүри метод булып тора.»;

4.18 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.18. Кандидатның йомгаклау балы индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган уртача арифметик балл, конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләгән башка конкурс биремнәре һәм тест нәтиҗәләре һәм башка шундый ук конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләре буенча кандидат җыйган баллар суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча, конкурс комиссиясе секретаре йомгаклау баллары кимү тәртибендә кандидатлар рейтингын формалаштыра.»;

4.21 пунктында «конкурс комиссиясе рәисе фикере» сүзләрен «утырышта рәислек итүче тавышы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре Министрлыгының конкурс комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклый дип билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**